**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Оштырма-Юмья авыл җирлеге башлыгы карары**

**30 октябрь, 2025 ел** **№ 7**

**«Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге Оштырма Юмья авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 12 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Оштырма Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Оштырма Юмья авылы, Мәктәп урамы, 42в йорты адресында урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.
2. 2025 елның 12 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Оштырма Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Оштырма Юмья авылы, Мәктәп урамы, 42в йорты адресында урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.
3. 2025 елның 12 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Оштырма Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Оштырма Юмья авылы, Мәктәп урамы, 42в йорты адресында урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.
4. 2025 елның 12 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Оштырма Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Оштырма Юмья авылы, Мәктәп урамы, 42в йорты адресында урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.
5. 2025 елның 12 ноябрендә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Оштырма Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Оштырма Юмья авылы, Мәктәп урамы, 42в йорты адресында урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.
6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2026 елда Кукмара муниципаль районының Оштырма-Юмья авыл җирлеге Оштырма Юмья

авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокլы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин;
- һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаганнары) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.
8. Оштырма-Юмья авыл башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
9. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
10. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы С.В. Тимофеев

ОГРН 1021607752737 ИНН 1623001692